РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**СОВЕТ ЧИСТОПОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ**

***Решение*** ***Карар***

**14 июнь 2023 ел** **Чистай шәһәре** **№ 23/8**

Чистай муниципаль районы Советының
“Татарстан Республикасының
«Чистай муниципаль районы»
муниципаль берәмлеге милкендәге,
индивидуаль эшкуарлар булмаган
һәм махсус салым режимын кулланучы
физик затларга кече һәм урта эшкуарлык
субъектларына биләүгә һәм (яисә) файдалануга
тапшыру өчен билгеләнгән муниципаль мөлкәт
исемлеген формалаштыру, алып бару һәм
бастырып чыгару тәртибен раслау турында”гы
2019 елның 17 апрелендәге 43/7 номерлы
карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 29 декабрендәге 605-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Чистай муниципаль районы Советының “Татарстан Республикасының «Чистай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге милкендәге, индивидуаль эшкуарлар булмаган һәм махсус салым режимын кулланучы физик затларга кече һәм урта эшкуарлык субъектларына биләүгә һәм (яисә) файдалануга тапшыру өчен билгеләнгән муниципаль мөлкәт исемлеген формалаштыру, алып бару һәм бастырып чыгару тәртибен раслау турында”гы 2019 елның 17 апрелендәге 43/7 номерлы карарына (Чистай муниципаль районы Советының 2020 елның 15 декабрендәге 3/10 номерлы карары нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

Карарның 1 нче кушымтасында:

2.2 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:

«2.2. Исемлеккә өченче затларның (кече һәм урта эшкуарлык субъектларының мөлкәти хокукларыннан тыш) хокукларыннан азат булган биналар (корылмалар), торак булмаган биналар (йортлар), шулай ук корылмалар, махсуслаштырылган транспорт чаралары (үзйөрешле машиналар), башка күчемле мөлкәт кертелергә мөмкин».

2. Әлеге карарны «Чистопольские известия» газетасында яисә Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Чистай муниципаль районының рәсми сайтында www.chistopol.tatarstan.ru урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны законлылык, хокук тәртибе һәм депутат эшчәнлеге мәсьәләләре буенча даими депутат комиссиясенә йөкләргә.

Чистай муниципаль
районы башлыгы Д.А. Иванов